**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ШӘДКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**(V чакырылыш)**

# РЕШЕНИЕ

**өченче утырыш**

**16 декабрь 2025ел** **№ 9** **Шәдке авылы**

**Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге Советының 15.11.2023 ел № 142 «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге Советының 15.11.2023 ел № 142 «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына (29.07.2024ел № 167, 01.11.2024 ел № 174 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 пунктның 2.1 пунктчасын «, билгеләнешен проектлаучы күпфатирлы йорт булган төгәлләнмәгән төзелеш объектларыннан тыш» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Теләче муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга: http://tulachi.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Шәдке авыл җирлеге Ф.Г. Кадыйров